ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл
җирлеге Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Нижнеберескинского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422743, ТР Әтнә муниципаль районы,
Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а
тел. 33-4-05, тел./факс 33-4-03

422743, РТ, Атнинский муниципальный
район, село Нижняя Береске, улица
Совета, д. 17а
тел. 33-4-05, тел./факс 33-4-03

# КАРАР

1 ноябрь 2022 ел — № 2

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге
Түбән Бәрәскә торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2022 елның 12 ноябренә 19.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктының Совет, Культурная, Мира, Зеленая урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2022 елның 14 ноябренә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктының Казаклар, Татарстан, Ленина, Центральная, Тукай урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2022 елның 15 ноябренә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктының Чишмәле, Новая урамнарында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты – 12 ноябрь 2022 ел 19.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты – 14 ноябрь 2022 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенының өченче этабын үткәрү вакыты – 14 ноябрь 2022 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү урыны – Түбән Бәрәскә авылы, Чишмәле ур., 21 нче йорт, күпфункцияле үзәк;
- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү урыны – Түбән Бәрәскә авылы, Казаклар ур.,8 нче йорт, ветеринар пункт янында;
- гражданнар җыенының өченче этабын үткәрү урыны – Түбән Бәрәскә авылы, Новая урамы, машина-трактор паркы янында.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетына тәкъдим итергә:

- 2022 елның 07 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт;
- сайлау хокукына ия булган Түбән Бәрәскә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Түбән Бәрәскә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итергә.

6. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Түбән Бәрәскә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) парк территориясен чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

4) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

5) Түбән Бәрәскә авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү).

“РИЗА” “КАРШЫ”

7. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17а йорт адресы буенча урнашкан информацион стендка урнаштырырга.

8. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.

СОВЕТ НИЖНЕБЕРЕСКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000476 ОГРН 1021606155405